**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**егерме бишенче утырыш**

**12 апрель 2023 ел** **№95** **Алан авылы**

**Алан авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 нче мартындагы №30 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне яңа редакциядә раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Алан авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 нче мартындагы №30 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне яңа редакциядә раслау турында» карарына (28.12.2019ел №171-1 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында, шулай ук Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәгә:

А) 3 пункт:

- 2 абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга;
- 3 абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 7 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

Алан авыл җирлеге башлыгы Б.Н.Хәсәнов